Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең
Яңа поселогы
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 20 ноябре, Яңа поселог № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Иске Гәрдәле авылында гражданнар җыены

Карар:

1. 2020 елда Әҗмәкәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (мең) сум күләмендә бер тапкыр түләүләрне, I нче һәм II нче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Әфганстан, Чечня, ЧАЭС авария чернобыль-ликвидаторлар катнашучылары, ялгыз карт гражданнар һәм көндезге формада белем алучы студентлар өчен, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләүне киметү һәм әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә түләү билгеләү, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдереләчәк:

1) юлларны ремонтлау;

2) парк территориясен һәм балалар мәйданчыкларын төзекләндерү;

3) балалар уен мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру;

4) зират коймаларын алыштыру;

5) зират җиһазларын саклау өчен бина урнаштыру буенча төзелеш материаллары, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу;

6) электр материаллары сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру.

2. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең Яңа поселогы гражданнарының авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында җыенның нәтиҗәсен игълан итәргә.

3. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең Яңа поселогында халык җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында " авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Әҗмәкәй авыл җирлеге башлыгы Р. Ф. Адиев